ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ<br>05.03.2024 | Иннополис шәһәре | КАРАР<br>16 |
|---|---|---|

«Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2021нче елның 13нче августындагы 88нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешендәге 21 пунктка ярашлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән, шулай ук норматив хокукый актны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2021нче елның 13нче августындагы 88нче номерлы карарына (15.07.2022 ел № 49, 05.10.2023 ел № 111 редакциядә үзгәрешләр белән.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы 9 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«планлаштыру структурасы элементы - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы, яр буе), бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләрен урнаштыру территорияләре;»;

1.2. Адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы 10 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

"урам-юл челтәре элементы - урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;".

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) басылып чыккан көннән үз көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында хәбәр ителергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге башлыгы С.А. Беловага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Р. Хуззятов